КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 август г.Казань № 845

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Экологик иминлекне тәэмин итүгә йөз тоткан иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 08 июнь, 432 нче карары белән расланган Экологик иминлекне тәэмин итүгә йөз тоткан иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Экологик иминлекне тәэмин итүгә йөз тоткан иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан

Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 8 июнь, 432 нче карары белән расланган Экологик иминлекне тәэмин итүгә йөз тоткан иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның сигезенче абзацында «максатлар һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"конкурс үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул конкурс үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яисә террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә, йә аларга карата массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булырга тиеш түгел»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Субсидияләр алу өчен коммерциягә карамаган оешмалар вәкаләтле органга, әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча гариза тапшыралар:

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән өстенлекле юнәлешләрне гамәлгә ашыру буенча әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча гамәлгә ашыру срогы 12 айдан артмаган проект (алга таба - проект);

коммерциягә карамаган оешманың уставы күчермәләрен;

гаризалар кабул итү вакыты башланырга өч айдан да соңга калмыйча коммерциягә карамаган оешма турында белешмәләр белән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр. Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә тапшырылмаганда, вәкаләтле орган аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала;

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә үз эшчәнлеген дәвам итү турында коммерциягә карамаган оешма тарафыннан мәгълүмат тапшыруны раслый торган документларның күчермәләре;

конкурс турында игълан урнаштырылган айга кадәр килгән айның беренче көне хәленә карата Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча белешмә кәгазе; Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан күрсәтелгән белешмәне тапшырмаганда,

вәкаләтле орган аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары юклыкны раслый торган җитәкче һәм коммерциягә кармаган оешманың баш хисапчысысы кул куйган белешмәләр;

үзгәртеп оештыру (конкурста катнашучы юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаган, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәгән, коммерциягә карамаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган булуы турында коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе һәм баш хисапчысы кул куйган белешмәләр;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе һәм баш хисапчысы кул куйган белешмәләр, дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функциясен үтәүче зат яисә коммерциягә карамаган оешманың баш хисапчысы турында белешмәләр булмау;

коммерциягә карамаган оешманың экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе һәм баш хисапчы тарафыннан кул куелган белешмәләр;

коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән өстенлекле юнәлешләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмәләр;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коммерциягә карамаган оешма турында, коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән заявка, конкурска бәйле коммерциягә карамаган оешма турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык;

Бер коммерциягә карамаган оешма бары бер заявка гына бирергә мөмкин, аның составында конкурста катнашу өчен бары бер проект кына тапшырыла.

Заявка тегелгән, номерланган һәм мөһер белән таныкланган һәм коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле затының имзасы куелган булырга тиеш. Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш.

Чистартулар һәм төзәтүләр, коммерциячел булмаган оешманың вәкаләтле заты имзасы белән расланган һәм мөһере белән беркетелгән төзәтмәләрдән тыш, рөхсәт ителми.

Заявка кәгазь һәм электрон чыганакларда (doc һәм pdf форматларында) турыдан-туры вәкаләтле органга тапшырыла яки элемтә оешмасы аша җибәрелә.

Гаризалар кабул итү срогы тәмамланганчы коммерциягә карамаган оешма ирекле формада язма гариза буенча заявканы, шул исәптән заявкага үзгәрешләр кертү һәм яңа заявка бирү максатында, чакыртып алырга хокуклы. Заявканы үзгәртү яисә аны чакыртып алу турында хәбәрнамә, әгәр аны үзгәртү коммерциягә карамаган оешма тарафыннан яңа заявка бирү юлы белән гамәлгә ашырылган булса яисә аны чакыртып алу турында хәбәрнамә вәкаләтле орган тарафыннан заявкалар бирү срогы чыкканчыга кадәр алынган булса, гамәлгә яраклы була.

Заявка, әгәр ул әлеге Тәртип таләпләренә туры килә икән, тиешле дип таныла, ә заявка биргән коммерциягә карамаган оешма аңа әлеге Тәртип тарафыннан куела торган таләпләргә туры килә.»;

3.10 пунктның өченче абзацында «аларга карата субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга» сүзләрен «вәкаләтле орган тарафыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне дәүләт (муниципаль) финанс контроле органы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә карата аларны тикшерүгә карата гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Субсидия алучы вәкаләтле органга субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү һәм чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшыра, аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүләрнең үрнәк формаларына теркәлгән формалар буенча кәгазьдә бирелә.»;

V бүлекнең исемендә «, максатларының» сүзен төшереп калдырырга;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Вәкаләтле орган, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглауны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашыра.».

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Экологик иминлекне тәэмин итүгә йөз тоткан иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 8 июнь, 432 нче карары белән расланган Экологик иминлекне тәэмин итүгә йөз

тоткан иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 2.4 пунктындагы өченче абзацының һәм 2.5 пунктындагы җиденче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы утыз икенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин